Республика Татарстан
Совет Старомензелябашского
сельского поселения
Сармановского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районының Иске Минзәләбаш
авыл җирлеге Советы

---

**РЕШЕНИЕ**

**КАРАР**

31.03.2026

№ 24

Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш
авыл җирлеге Советының аерым
карарларының үз көчләрен югалтуын тану
турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы, «Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указының 4 пунктын үтәү турында" Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 13.03.2026 елгы 09/13-09/1259 номерлы хаты, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларының үз көчен югалтуын таныргa:

- 29.08.2017 ел, № 17 «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Сарман муниципаль районы «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфалары тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында»
- 21.07.2021 ел, №11 « 29.08.2017 ел № 11 карары белән расланган «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Сарман муниципаль районы «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфалары тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында» үзгәрешләр кертү;
- 11.07.2022 ел, № 12 « Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында халыкка җиткерергә
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе А.Н.Габдрахманов